ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ | г. Казань | Боерык

23.09.2021 № 288 - од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 07.06.2018 ел, 145-од номерлы боерыгы белән расланган, («Махсус саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 3[1] статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максаты белән боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 07.06.2018 ел, 145-од номерлы боерыгы белән расланган, («Махсус саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 3[1] статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән

капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга. (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 12.12.2009 ел, 392-од номерлы боерыгы, 27.04.2020ел.125-од номерлы, 05.11.2020 ел, 338-од номерлы, 02.06.2021 ел, 161-од номерлы, 31.08.2021 ел 257-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С.Батков

Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
23.09.2021 ел 288-од номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 07.06.2018 ел, 145-од номерлы боерыгы белән расланган, («Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр.

Боерыкның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын расларга»;

Административ регламентта:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты»;

1 нче бүлектә:

1.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты (алга таба - Регламент), («Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.( алга таба – дәүләт хезмәте)»;

2 нче бүлектә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы.

Объектны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирү (алга таба – объектны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт)»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт;

объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (алга таба-баш тарту турында белдерү кәгазе);

объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең дубликатын бирү;

объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирүдән баш тарту.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты.

Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү яки объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирүдән баш тарту, Рөхсәтнең дубликатын бирү процедурасын гамәлгә ашыру вакыты, рөхсәтнамәне теркәгәннән соң, 5 эш көне.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә гариза һәм кушып бирелә торган документларны Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Комитетка тапшыру тәэмин ителә. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү яки бирүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру вакытында КФҮтә булу вакыты һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен КФҮкә Комитеттан тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче килгән көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска, Республика порталындагы шәхси кабинетка) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге,гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе.

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен Рөхсәт бирү турында гариза. ( әлеге Регламентка 1 нче кушымта)

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен Рөхсәт бирү турында гаризага түбәндәге документларны теркәргә кирәк:

1) капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелешне, реконструкцияне төзелеш подряды килешүе нигезендә гамәлгә ашыру очрагында);

2) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объекты параметрларының проект документларына, (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү өлешендә (алга таба - РФ ШтК), шул санда энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетик ресурсларны исәпкә алу приборлары белән җиһазлану таләпләренә туры килүен раслый торган һәм төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы, төзү подряды килешүе нигезендә төзелешне, реконструкцияне гамәлгә ашырган очракта, төзүче яки техник заказчы,

шулай ук төзелеш контроле шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан ) имзаланган документ.

3) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник шартларга туры килүен раслаучы һәм инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешма вәкилләре (алар булганда) кул куйган документлар;

4) төзелгән, реконструкцияләнгән линияле объекттан кала, җир бүлемтеге чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының, инженер-техник тәэмин итүче челтәрләрнең урнашуын һәм җир бүлемтегенең планлы оешмасын чагылдыра торган һәм төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы, төзү подряды килешүе нигезендә төзелешне, реконструкцияне гамәлгә ашырган очракта, төзүче яки техник заказчы, шулай ук төзелеш контроле шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан ) имзаланган схема;

5) куркыныч объектта һәлакәт нәтиҗәсендә зыян китерү өчен,куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү турында Россия Федерациясе кануннары белән тәңгәл килеп, куркыныч объектта һәлакәт нәтиҗәсендә зыян китерү өчен,куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсен төзүне раслаучы документ;

6) әлеге объектны реставрацияләү, консервацияләү, ремонтлау һәм аны заманча куллану өчен уңайлы иткән вакытта, 25.06.2002 елдан 73-ФЗ "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мирас һәйкәлләре) турында"гы Федераль канун белән билгеләнгән, туры килүче мәдәни мирас объектларын саклау әгъзасы белән расланган, мәдәни мирас объектын саклап калу буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты;

7) 13.07.2015 елдан 218-ФЗ номерлы "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында"гы Федераль канун белән тәңгәл килеп әзерләнгән, капиталь төзелеш объектының техник планы.

8) мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (шәхси мөрәҗәгать иткәндә). Республика яисә Бердәм порталы аша мөрәҗәгать иткәндә , шәхесне таныклаучы документның «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлүне раслаганда тикшерелә.;

9) мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, Мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итәргә вәкаләтләрен раслаучы документ.

Әлеге пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагында булмаган булса, мөстәкыйль җибәрелә. Әгәр әлеге абзацта күрсәтелгән документлар дәүләт хакимияте

органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган оешмалар карамагында булса, мондый документлар, әгәр мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль тапшырмаган булса, Комитет тарафыннан соратып алына.

Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең тиешле этабына кагылышлы өлешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата (булганда) объектны файдалануга тапшыруга элегрәк бирелгән рөхсәтләр турында белешмәләр күрсәтелә.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирү өчен гариза бирүче Комитетка әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирү турында язма гариза җибәрә.

Дәүләт хезмәте алу өчен, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирү турында гариза бланкларын гариза бирүче Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкларның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушылып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып җибәрелергә мөмкин:

1) Комитетка шәхсән яисә почта аша кәгазь иядә һәм «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

2) КФҮ аша кәгазь иядә һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

Гариза биргәндә мөрәҗәгать итүчегә КФҮтән гариза җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм электрон гариза бирү датасы белән расписка бирелә;

3) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада.

Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының, Бердәм порталның шәхси кабинетында һәм электрон почта аша теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелгәне турында белдермә килә.

Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә гариза гади электрон имза белән имзалана.

Мөрәҗәгать итүчегә, гади электрон имза алу өчен, теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алуны стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик

затларның вәкилләре гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Запросны Республика порталы, Бердәм портал аша биргәндә гариза бирүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларны электрон рәвештә тапшыра»;

2.7. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) белдерү кәгазен (гаризаны)дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтенә керми торган дәүләт хакимияте органына тапшыру;

2) белдерү кәгазе (гариза) формасында кырларны тулысынча тутырмау, шул исәптән Республика порталында, Ббердәм порталда белдерү кәгазенең (гаризаның) интерактив рәвешендә;

3) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларны тапшырмау;

4)тапшырылган документлар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытта үз көчләрен югалткан булса (шәхесне раслаучы документ; мөрәҗәгать итүче вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрен раслаучы документ);

5) кәгазьдә тапшырылган документта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләр булу;

6) электрон рәвештә бирелгән документларда, алар аркасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган бозылган урыннар булу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле белдерү кәгазе (гариза) һәм документлар, аларны бирү форматларына карата таләпләрне бозып, электрон формада бирелгән һәм (яки) укылмый торган булу;

8) 63-ФЗ номерлы Федераль законның $1^1$ статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон култамганың чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган очракта.

2.13 пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Республика порталына, Бердәм порталга (техник мөмкинлек булганда) электрон рәвештә кергән гариза, Республика порталында, Бердәм порталда запросларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.»;

2.15 пунктының унсигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте экстрориториаль принцип буенча яки комплексны соратып алу составында күрсәтелә.»;

2.15 пунктының унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Комитетта, Республика порталынын, Бердәм порталның шәхси кабинетында, КФҮтә алырга мөмкин.»;

2.16 пунктта:

дүртенче абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм» сүзен өстәргә;

жиденче абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм» сүзен өстәргә;

тугызынчы абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм» сүзен өстәргә, «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм »сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «Республика» сүзеннән соң « Бердәм Россия»сүзен өстәргә;

унтугызынчы абзац «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм» сүзен өстәргә;

3 нче бүлектә:

3.1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7) объектны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт дубликатын әзерләү, бирү яки бирүдән баш тарту.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәте алу өчен, документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә. Кирәк булганда, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче Комитетка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон документ рәвешендә электрон почта аша, (e-mail: ojm@tatar.ru), кәгазь иядә почта аша, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru), дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерү өчен мөрәҗәгать итә..

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка сораулар буенча мәгълүмат бирә һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ сайтыннан иректе файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала. (http://mfc16.tatarstan.ru/)

Шулай ук мөрәҗәгать итүче Республика порталында, Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация алырга

хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.»;

3.3.1 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Гариза Комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизация уза;

Республика порталында, Бердәм порталда электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

документларны электрон формада яки электрон документлар үрнәкләрендә электрон гариза формасында беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (гариза формасында тиешле билге куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (тиешле электрон гариза формасында төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында белдерү кәгазе ала.

КФҮ аша гариза биргәндә:

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны КФҮкә тапшыра.

Гаризаны кабул итүче КФҮ хезмәткәре, КФҮ эше Регламентында каралган процедураларны башкара.

КФҮ белгече кабул ителгән һәм теркәлгән документларны КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Комитет һәм КФҮ арасында эш тәртибе хезмәттәшлек турында килешү, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр-КФҮ эше Регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. Гаризаны КФҮ аша биргән очракта, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар КФҮ эше регламентында һәм КФҮ белән Комитет арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза»;

3.3.2 пунктының бишенче абзацында «Региональ» сүзеннән соң « ,Бердәм Россия»сүзен өстәргә;

3.5.1 пунктының җиденче абзацында «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм » сүзен өстәргә;

3.6.2 пунктында:

икенче абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм» сүзен өстәргә;

өченче абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм » сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «Республика» сүзеннән соң « ,Бердәм »сүзен өстәргә;

киләсе редакциядә 3.6.3 пунктын өстәргә:

«3.6.3. КФҮкә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе артыннан мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә электрон документ нөсхәсе рәвешендә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен кәгазьдә бирә. Мөрәҗәгать итүченең соравы буенча, электрон документ нөсхәсе белән бергә, аңа электрон документның нөсхәсе алынма иягә язып бирелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, гариза бирүченең килү көнендә КФҮ эше Регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.»;

3.8 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Объектны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт дубликатын әзерләү, бирү яки бирүдән баш тарту.

3.8.1. Бүлек белгече:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) кирә торган номерда бирелгән документларны кабул итү датасы турында тамга белән гариза күчермәсен тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза.

3.8.2. Бүлек белгече:

Объектны файдалануга тапшыруга бирелгән рөхсәт дубликатын әзерли, объектларны файдалануга тапшыруга бирелгән рөхсәт дубликатының сул ягында «Дубликат» штампын куя;

гариза бирүчегә объектны файдалануга тапшыру өчен бирелгән рөхсәт дубликатын әзерләү турында хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерү өчен юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченә гариза җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән әзерләнгән объектны файдалануга тапшыру өчен бирелгән рөхсәт дубликаты.

3.8.3. Бүлек башлыгы объектны файдалануга тапшыру өчен әзерләнгән рөхсәт дубликатының дөреслеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имза куярга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура объектны файдалануга

тапшыруга рөхсәт дубликаты һәм хат проекты Бүлек башлыгына килешүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә кул куюга юнәлдерелгән объектны файдалануга тапшыруга бирелгән рөхсәт һәм хат проекты.

3.8.4. Комитет рәисе аңа кушып бирелә торган объектны файдалануга тапшыруга бирелгән рөхсәтнең дубликатына һәм хат проектына кул куя һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән хат проекты, объектны файдалануга тапшыруга бирелгән рөхсәт дубликаты.

3.8.5. Бүлек белгече Комитет рәисе кул куйган дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны терки, ул объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликаты белән бергә гариза бирүчегә яки аның ышанычлы затына (ышаныч кәгазе булган очракта) расписка белән бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче яки аның ышанычлы заты килгән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән хат һәм объектны файдалануга тапшыруга бирелгән рөхсәтнең дубликаты.»;

әлеге Регламентка 1 нче кушымтаның нумерация язылышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта»;

нумерационный заголовок приложения №2 к настоящему Регламенту

әлеге Регламентка 2 нче кушымтаның нумерация язылышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта»;

әлеге Регламентка 3 нче кушымтаның нумерация язылышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта»;

әлеге Регламентка 4 нче кушымтаның нумерация язылышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта»;

әлеге Регламентның 5 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

Кемгә: ______________________________

(физик зат, шәхси

______________________________

эшкуарның фамилиясе, исеме,)

______________________________

атасының исеме (булса)

______________________________

/юридик затның атамасы)

Баш тарту турында белдерү кәгазе

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты ______________________________________________

(оешманың атамасы, ИНН/КПП, ОГРН,

______________________________________________________________

урнашу урыны, физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булса) паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы)

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәтенең атамасы)

______________________________ ______________________________

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә, күрсәтү өчен документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

(кирәклесенең астына сызарга)

Баш тарту сәбәбе:______________________________________

____________________ ____________ ____________________

(вазыйфа) (имза) (исем, фамилия, атасының исеме(булса);

Регламентны киләсе эчтәлекле 6нчы кушымта белән тулыландырырга:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына

кемнән:

(ФИО, паспорт мәгълүматлары/

мөрәҗәгать итүченең исеме

гражданинның шәхси счетының иминият номеры

-СНИЛС (физик затлар өчен),

ИНН; житәкченең исеме,фамилиясе,

атасының исеме;

банк реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с,

БИК) юридик һәм почта адресы, телефон;

(теләк буенча) электрон почта адресы

## Объектны файдалануга кертү өчен бирелгән рөхсәтнең дубликатын бирү турында гариза

(дәүләт адреслар реестры нигезендә, адреслар бирүгә вәкаләтле дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органы

актының реквизитларын күрсәтеп, капиталь төзелеш объектының адресын бирү, үзгәртү

турында ; линияле объектлар өчен - Россия Федерациясе субъекты(лары), муниципаль берәмлекнең

төре һәм атамасы, шулай ук аның атамасы рәвешендә урнаштырыла;

әгәр линия объекты яки аның өлеше(өлеше) торак пункт чикләрендә урнашкан булса, тиешле

муниципаль берәмлекләрдә торак пункт(лар) атамалары.

______________________________ адрес буенча урнашкан

(файдалануга тапшыруга рөхсәт нигезендә,капиталь төзелеш объектының (этабының) атамасы, исәпкә

алынучы реконструкцияләнә торган объектның күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы кадастр номеры)

капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру өчен бирелгән рөхсәтнең дубликатын бирүегезне сорыйм.

Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру өчен бирелгән рөхсәтнең реквизитлары (датасы, номеры)_______________________________________________

Туры килү турындагы белдерү кәгазенең дубликатын бирү зарурлыгы түбәндәге хәлләр белән бәйле____________________________________

Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру өчен бирелгән рөхсәтнең дубликатын кәгазьдә яки электрон документ формасында әзерләвегезне сорыйм.

(кирәкмәгәнне сызып ташларга)

| | | |
|---|---|---|
| ________________ (вазыйфа) | ________________ (имза) | ________________ (Ф.И.О.) |

«____»____________________20__ел»;